СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

12 ноябрь, 1997ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 127 (8139) | Бәясе билгеләнгәнчә

*Татлы тамырны - дәүләткә*

## Хафизовлылар өлеше - иң ишлесе

***Хафизов исемендәге хуҗалык игенчеләре гаять катлаулы табигать шартларында да дәүләткә шикәр чөгендере сату буенча килешү йөкләмәсен уңышлы үтәп чыга алдылар. Аларның йөкләмәсе арада иң ишлесе - 10200 тоннадан артык булуын да исәпкә алсак, хафизовлыларның хезмәт җиңүе икеләтә куанычлы. Хуҗалык чөгендерне йөкләмәдән тыш сатуны да дәвам иттерә.***

# БЕРСЕН ТӨГӘЛЛИСЕ, ИКЕНЧЕСЕН...

*Район хакимиятендәге киңәшмәдән*

Дүшәмбе көнне район хакимиятендә хуҗалык җитәкчеләре һәм шефлык итүче, хезмәт күрсәтүче предприятиеләр һәм оешмалар башлыклары катнашында узган киңәшмәдә сүз нигездә ике төп тармак турында барды. Аларның беренчесенә килгәндә, сүз шикәр чөгендерен заводка озатып бетерүне тиз арада төгәлләү хакында. Киңәшмәдә беренче булып сүз алган оратор - район авыл хуҗалыгы һәм азык төлек идарәсе башлыгы Ф.М.Дәүләтшин иң элек шикәр чөгендере тапшыру буенча килешү йөкләмәсен арттырып үтәгән хуҗалыклар хезмәтчәннәренә рәхмәт белдерүдән башлады. Узган шимбә көн мондыйлар рәтенә Хафизов исемендәге хуҗалык та кушылды. Әлегә чөгендерне иң күп тапшырган бу хуҗалыктан заводка әле дә машиналар килә тора. Ә менә чөгендер ташуны тәмамлаган хуҗалыклардан бишесенең быел килешү йөкләмәсен тутыра алмаулары аяныч. Район буенча дәүләт заказын үтәп чыгу өчен тагын 28 мең тонна татлы тамыр тапшырасы бар.Шуңа да киңәшмәдә бу эшне ничек тә нәтиҗәлерәк оештыру, шул максатларга бирелә торган техниканың, бигрәк тә автотранспортның җитештерүчән файдаланылуына ирешү уңаеннан сүз кискен булды, кайбер хуҗалык җитәкчеләренә җитди җавап тотарга да туры килде.

Икенче бер мөһим тармак - терлекчелеккә килгәндә исә сөт җитештерү, бигрәк тә аны хәзерләүнең күзгә күренеп кимүгә баруы нык борчый. Кызганычка каршы, моның өчен урыннарда да шулай ук җитди борчылу сизелми шул әле. Шулай булмаса, күпчелек хуҗалыкларда малларны карау һәм ашатуның иң элементар таләпләре дә санга сугылмауны, аерым алганда, рационның гаять ярлылыгын, азык була торып та сыерларның кайчак коры саламга калдырылуын ничек аңлатасың. Өзлексез эшләп торган шикәр заводының төп базы тулы булып та, чөгендер китергән машиналарның юл уңаенда төп төямичә буш йөрүе гаҗәп. Болай да ягулык кытлыгы якадан алган заманда куәтле техниканы яртылаш кына файдалану һич тә акланмый.

Киңәшмәдә көн кадагында торган башка мөһим мәсьәләләр дә кузгатылды. Шулардан хуҗалыкларда булган матди байлыкка хуҗаларча караш, аларның сакланышын тәэмин итү, урлатуларны чикләү буенча эшне көчәйтү зарурлыгы ассызыкланды. Бу уңайдан район эчке эшләр бүлеге башлыгы урынбасары В.Л.Гаврилов махсус сүз алды.

Киңәшмә эшенә хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев йомгак ясады.

Яңалыклар

## Лекторийлар тәмам. Дәвамы - алда

Яшүсмерләр арасында негатив күренешләрне кисәтү буенча координацион совет октябрь аенда барлык шәһәр мәктәпләрендә балалар һәм ата - аналар катнашында лекторийлар үткәрде. Табиблар, хокук тәртибен саклау органнары вәкилләре, мәгариф бүлеге хезмәткәрләре катнашында уздырылган әлеге чаралар балалар һәм ата - аналарның киң катнашында, зур оешканлык белән үтте. Авыл мәктәпләрендә исә мондый чараларны үткәрү директорларның укыту - тәрбия эше буенча урынбасарларына йөкләнгән иде.

Совет бүген яшүсмерләр арасында негатив күренешләрне кисәтү эшен тагын да нәтиҗәлерәк итү өчен яңа программа хәзерли. Февральдә хокук айлыгы чорында гамәлгә ашырылачак ул.

Яңалыклар

## Иске Әмзәдә - алтын туй

Узган бәйрәмнәр Иске Әмзәдә яшәүче Кәлимуллиннар гаиләсе өчен икеләтә сөенечле булды. Шушы көннәрдә гаиләдә «алтын туй» үтте. Дәһшәтле сугыш чорында тракторчы булган, аннан соң да намуслы хезмәт куйган Наилә апа һәм зур оештыру осталыгына ия, берничә дистә ел өрөзлексез бригадир булган Мәҗит ага Кәлимуллиннарның бергә яши башлауларына ярты гасыр - 50 ел тулды.

Тантана күңелле үтте. Анда Кәлимуллиннарның гаиләдә яхшы тәрбия алып, җәмгыять өчен файдалы кеше булып җитешкән балаларының алтысы да катнашты. Оныкларының, туганнарының котлавы да өлкәннәр күңеленә хуш килде.

Яңалыклар

## Телетапшыру кунагы - безнең Рамил

Татарстан телевидениесенең «Җомга көн кич белән» дигән популяр тапшыруының соңгысына чакырылган кунаклар арасында Норлат егете, хәзер Түбән Камада яшәп иҗат итүче Рамил Мифтахов та бар иде. Әле күптән түгел генә Норлат сәхнәсендә чыгыш ясаган «Мунча ташы» миниатюралар театры артистлары Рамилебезнең берничә җырын башкарып куандырган булсалар, инде менә Казан телетапшыруларын караучы тамашачылар үзешчән композиторыбызның үзен дә күрделәр. Танылган җырчы Габделфәт Сафин бу тапшыруда Рамилнең Югары норлатлы Фәүзия Мөхәмматова сүзләренә язган «Чияләр» җырын башкарып, ул җырның язылу тарихы, әсәрнең үз кулына ничек килеп эләгүе турында да сөйләп үтте. Рамил үзе дә җыр язуга ничек керешеп китүе турында сөйләп алды. Ә тапшыру Рамил Мифтаховның Роберт Миңнуллин сүзләренә язган «Сакланган йөрәк кирәк» дигән яңа җыры белән тәмамланды.

# Җырлатты да, биетте дә... ярминкә



Көндәлек базар халыкның киң ассортиментта товар һәм азык - төлек продуктларга булган ихтыяҗын тулы канәгатьләндерсә дә, халык соңгы вакытта еш үткәрелә торган ярминкәләргә дә теләп йөри. Районның сәүдә мәйданында үткән ярминкәләрнең соңгысында да бәгырьләргә үтәрлек булып искән салкын җил генә дә норлатлыларның ярминкәгә чыгуына тоткарлык тудыра алмады: кышка кереп барганда кәбестәсе, кабагы, ашлыгы, ите - ние - барысы да кирәк бит. Ярминкә элеккеләренә караганда чагыштырмача таррак кысаларда үтсә дә, Мичурин исем., «Кондырча», «Татарстан», «Игенче», «Чирмешән» КХАлары, Гәйтән, Киекле авыл Советлары, районның сәүдә оешмалары элеккеге гадәт буенча гөр килеп хезмәт күрсәттеләр халыкка. Киң асортиментта азык - төлек продуктлары, промышленность товарлары белән сәүдә иттеләр алар. Тимер юл ОРСының, һәрвакыттагыча, бу юлы да зур хәзерлек белән килүе сизелде ярминкәгә. Бер рәткә тезелгән һәм милли бизәкләр төшерелгән 7 - 8 сәүдә павильонында нәрсәләр генә юк иде. Мичтән яңа гына чыккан данлыклы тимер юл ипие, ике җирдә ут өстендә чыжлаган шашлык, кызарып пешкән коймак. Өстәлдә күмер самовары «җырлап» утырды.



\- Коллектив ярминкәләрнең һәркайсына җитди әзерләнә. Бу юлы да витриналар, өстәлләребезне бәйрәмчә, күңел күтәрерлек итеп бизәргә тырыштык,- ди бүлек начальнигы Н.С.Сафиуллин.

Бәйрәм күтәренкелеге дигәннән, бу көнне район хакимиятенең мәдәният бүлегенең дә моңа саллы өлеш кертүен әйтми калу мөмкин түгел. Ачы җил дә район үзешчәннәре тарафыннан башкарылган татар, рус, чуваш халык җырларын «басып» китә алмады. Бозлы «сәхнәдә» биергә дә җөрьәт иттеләр хәтта. Ярминкәгә килгән халык өчен бер бию дискотекасы оештырсалар, кече яшьтәгеләр өчен аерым бер күңел ачу программасы хәзерләнгән иде.

\- Ярминкәләр кирәк... Билгеле инде, кесәңдә акчаң булганда бик теләп барасың анда. Ә булмаса?

\- Кышка запас туплавыбыз әйбәт.

\- Биш ай хезмәт хакы биргәннәре юк. Берни дә алмадым, аның каравы әртисләргә кушылып җырладым, биедем.

Ярминкә барышында фикерләрен белешкән кешеләрдән шундыйрак җаваплар ишеттек без. Ни эшләмәк кирәк, һәр кешенең һәр нәрсәгә үз мөнәсәбәте шул.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## *Тантанага килегез!*

Бисмиллаһи рахманир рахим! Шикәр заводы бистәсендә кыска гына вакытта мәдрәсә бинасы төзелде. Халык үтенече буенча барган бу төзелешкә хакимият башлыгы урынбасары Ю.В.Терентьев якыннан торып булышлык итте. Районның күп оешмалары һәм хуҗалыклары шулай ук ярдәмнәреннән баш тартмадылар. Бу уңайдан «Таң», «Якты Күл», «Рассвет», «Кондырча» КХАлары рәисләренә без аеруча рәхмәтлебез. Шулай күмәк тырышлык белән мәдрәсәбез халык карамагына тапшырыр дәрәҗәгә җиткерелде. Ул вакытлыча мәчет вазифаларын да үтәячәк. Шәһәребез мөселманнарын әлеге игелекле йортны ачу тантанасына килергә чакырабыз. Ул 13 нче ноябрь көнне иртәнге 9 сәг. 30 минутта башланачак. Тантанага рәхим итегез!

**Бистә мөселманнары.**

# Россиянең хәрби дан көннәре

**7 ноябрь - Кузьма Минин һәм Дмитрий Пожарский җитәкчелегендә халык көчләре тарафыннан Мәскәүне поляк интервентларыннан азат итү көннәре (1612 ел).**



17 гасыр башында Польшаның һәм Швециянең агрессив феодаль даирәләре рус җирләрен басып алу һәм рус халкын кол итү максатыннан, рус дәүләтендәге эчке хәлнең кискенләшүеннән файдаланып сугыш башлый.

Польша короле Сигизмунд III, поляк - литва магнатлары ярдәменнән файдаланып, 1609 елда рус дәүләте чикләренә бәреп керә. Новгород өлкәләре вакытлыча швед феодаллары тарафыннан оккупацияләнгән булалар. Василий Шуйский хөкүмәте һәм аңа алмашка килгән җиде боярлылык халык массаларын интервентларга каршы көрәшкә оештыра алмыйлар.

1610 елда сатлык җан боярлар поляк отрядларына Мәскәү капкасын ачкач, халык массасының киң азатлык хәрәкәтләре көчәя. 1611 елда ополчение барлыкка килә, әмма җитәкчеләре арасында чыккан фикер төрлелеге һәм сатлык политика нәтиҗәсендә тиздән тарала.

Бер халык ополчениесен оештыручы һәм җитәкчесе булып Түбән Новгород купецы, земский староста Кузьма Минин тора. Ул күрше кнэзьлекләргә халыкны туплап басып алучыларга каршы көрәшкә чыгарга чакырып мөрәҗәгать итә. Ополчениегә земский кешеләр, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр, казак таборлары керә. Хәрби начальник сыйфатында Дмитрий Пожарский тартыла.

Гаскәр җыеп, Мәскәүгә походка китәләр. Юл уңаенда Замоскворечье һәм Кремльгә янәшә бистәләрне азат итеп, Кремльне камап алалар. Тиздән камалышта калучыларның хәле кыенлаша. Ашарга юклыктан, тыныч халыкны талау, үтерүләр башлана. Полковник Бутило һәм Струев аерым



шартларда Мәскәүне бирергә тәкъдим ясап сөйләшүләр алып барырга киләләр. Әмма Пожарский тулы берсүзсез капитуляция таләп итә. Полковниклар һәм поляк солдатлары байракларын һәм коралларын ташлап, әсирлеккә бирeләләр. Шунда ук сатлык җан боярлар да әсирлеккә бирeләләр.

1612 елның 7 ноябрендә Минин һәм Пожарский ополчениесе отрядлары Кремльгә керәләр. Мәскәү чит ил басып алучыларыннан азат ителә.

Минин хәрби хәрәкәт вакытында зур батырлык һәм хәрби оештыру сәләте күрсәтә.

Дмитрий Пожарский да талантлы хәрби начальник, кыю сугышчы һәм акыллы политик буларак танылa.

Мәскәүне азат итүдә алар батырлыгын мәңгеләштерү максатында, 1618 елда Мәскәүнең үзәгендә Кызыл мәйданда Минин һәм Пожарскийга һәйкәл куела.

**Материалны И.САНДЛЕР әзерләде.**

# ЕЛЫНА - 1119 КАРАР

Узган ел Татарстан хөкүмәте 1119 карар чыгарган. Министрлар Кабинетының секретариат җитәкчесе Нәҗип Бакиров әйтүенә караганда, алар елына 2000гә якын документ әзерләп, дөньяга чыгаралар. Ә хөкүмәт җитәкчеләре исеменә килүче документлар саны унар меңгә җитә. Узган ел Премьер - министр исеменә 8642 данә җаваплы кәгазь килгән.

- Бюрократия йокламый, - ди бу уңайдан Н.Бакиров - чиле - пешле кәгазьләрне әвәләп кенә торалар. «Чи» юлламалар бигрәк тә Финанс министрлыгыннан керә.

Аппарат җитәкчесенең Хөкүмәт утырышында хәбәр итүенчә, Министрлар Кабинетында берьюлы 100әр карар әзерләнә икән. Нибары 103 кеше эшләгән Министрлар Кабинеты коллективы өчен бу бик зур йөк булып чыга түгелме? Карарларның үтәлеп бетмәве, кайчак туу белән үлүләре дә менә шуның белән бәйледер бәлки.

**(«Юлдаш» газетасының октябрь ае санынннан).**

## Предприятие эзләнү юлында

# ЗАМАНА ЧИРЕ

## Саннар ни сөйли?

*«Сельхозтехника»ның гөрләгән чаклары булды. Кыр эшләре төгәлләнүгә үк хуҗалыклар график нигезендә ремонт таләп итүче барлык авыл хуҗалыгы техникасын берләшмәгә китереп ремонтлаталар, үзләре дә бу эштә якыннан торып катнаша торганнар иде. Ә хәзер...*

*Берләшмә тик тора дип әйтергә җыенмыйбыз. Быелның тугыз аенда, мәсәлән, «Сельхозтехника» аркылы район хуҗалыкларының 51 тракторы, 28 комбайны, 26шар азык җитештерү һәм чүгендер казыту техникасы үткән. 72 данә дизель двигателе, 33 автомашина ремонтланган, аерым детальләр - узеллар төзәтелгән. Барлык цехлар - мастерской, линия - монтаж узелы, техник хезмәт күрсәтү һәм кислород станцияләре, автотранспорт - гомумән, тулы көчкә эшләгәннәр. Ел ярымлап элек ачылган автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү станциясе дә үз бурычын әйбәт үтәгән. Яңа эш - ашлык төягечләр ясауны да уңышлы үзләштергәннәр берләшмәдә. Кыска вакыт эчендә ясалган 10 төягечнең 5се сатылган. Шушы чорда 3 миллиард сумлык запас частьләр реализацияләнгән.*

*Азмы бу, күпме? Элеккеге еллар белән чагыштырганда аз, билгеле. Авылларның берләшмәгә ышанычлары шул кадәр генәме, әллә башка нәрсә сәбәплеме моңа?*

## БУРЫЧЛЫ «ҮЛСӘ» ӘГӘР...

- «Сельхозтехника»да ремонтланган техника ышанычсыз. Шуңа аны үзебездә төзәтү хәерлерәк.

- Ремонт өчен түләргә акча юк.

Хуҗалыкларда булганда шундый һәм шуңа якын фикерләрне еш ишетергә туры килә. Кайчак «Бу оешманың район өчен бөтенләй дә кирәге юк» дигән фикер дә ишетелгәли хәтта. Ярар, әлеге проблемага берьяклы гына якын килеп, оешма ябылган дип фаразлыйк. Бу нәкъ урак өстенә дә туры килгән дип күз алдына китерик. Теге яки бу хуҗалыкта комбайн яки башка төр техника ватылса, белгечләр ярдәм яисә запас часть сорап кая ашыгырлар иде икән? Һичшиксез, берләшмәне искә төшерерләр мөгаен. Гадәти һәм ял көннәрендә кулыңа доверенность кәгазе тотып килеп тә, күпме кирәк, шул кадәр запас часть төяп җибәрүче бүтән оешма юк бит Норлатта. Әнә, «Комбайн» КХАсы гына да шулай бер тиен түләмичә, кәгазьгә ышандырып, биредән 843 миллион сумлык запас часть алып киткән. МСОның бурычы 634, «Үрнәк»неке 670 миллион сумга җыелган. «Әлмәт» КХАсының өч ел дәвамында аз - азлап бурычка керүе 617 миллионга җиткән бүген. Ә әҗәтне түләү турында һичкемнең башы авыртмый.

Ә Т - 70 тракторлары белән хәл ничек торыр иде? Татарстанның байтак районнары безнең «Сельхозтехника» ярдәменнән башка аларны төзәтә алмаганда, октябрьлеләр генә мөстәкыйль рәвештә әллә ни майтара алмаслар иде, мөгаен. Ә башка төр техникага җитди ремонт таләп ителгәндә ни эшләргә? Шулай бер хуҗалыкта тракторларны үзләрендә ремонтларга ниятләп, терсәкле валлар кайтартып төзәтеп куйганнар иде, берничә көннән үк двигателе «шакылдады». Янә валын алыштырып трактор эшләп китә алмагач кына китерделәр аны берләшмәгә. Билгеле инде, хуҗалыкларның үзләрендә техниканы кем әйтмешли, тезгә куеп төзәткәнгә караганда, махсус җиһазлар ярдәмендә ремонтлау тизрәк тә, ышанычлырак та. Берләшмәдә обкатка үткән двигательнең хезмәт итү срогы да икеләтә - өчләтә арта, билгеле. «Татагропромстандарт»тан килгән белгечләрнең безнең район «Сельхозтехника»сындагы җиһазларның барысын да диярлек дәүләт стандартлары таләпләренә җавап бирә дип табулары да шул хакта сөйли). Бу эшне кесәдән акча чыгармыйча «йомшак агай»ны «бурычлы үлми чирле үлә» дип ышандырып кына башкару хуҗалыклар өчен икеләтә кулай инде. Ә аерым - аерым бурычлардан берләшмәгә 9 миллиард бурыч җыелуы, аның үз эшчеләренә хезмәт хакы да бирә алмыйча 6 миллиардлап бурычы җыелуы ни аларга... Югыйсә, шушы бурычларның бер өлешен генә җыйнап алу да предприятиегә производствода эшне җанландыру өчен башка төрле мөмкинлекләр бирер иде. Аерым алганда, соңгы вакытта сатып алынган мөһим җайланма - барлык марка терсәкле валларны плазма белән ябыштыру агрегатын эшкә җигә, реаль бурыч - француз сабаннары җитештерүгә керешә алырлар иде. Эшләүчеләргә хезмәт хакы түләү, налоглар буенча бурычларны каплау һәм башкалар турында әйтеп торасы да юк инде.

Ахыр чиктә предприятиенең тулы бер микрорайонны тоту буенча эше дә бераз алга китәр иде, мөгаен.

## МИКРОРАЙОН ҖЫЛЫ КАРАШ СОРЫЙ

«Сельхозтехника»ның үз торак микрорайоны бар. Бүгенге көнгә берләшмәнең торак фонды 300ләп фатир тәшкил итә. Балалар бакчасы, кибет, медпункт, мунча белән бергә җәмгысе 161 мең 338 кубик метрга җыела ул. Әлеге мәйданны ягып җылыту өчен генә дә сезонга 3.200 тонна (1 миллиард 800 миллион сумлык) сыек ягулык таләп ителә. Арзан ягулык белән файдаланыр көннәр турында хыялланырга гына кала - котельня газ белән ягып җылытуга җайланмаган.

Шул кадәр торак фондын җылыту бер нәрсә, аның бит әле су белән тәэмин итү, чүбен чыгару кебек тавык чүпләп бетерә алмаслык һәм иң мөһиме зур чыгым таләп итүче тагын дистәләгән башка проблемалары да бар. Ә ЖКХ өчен җаваплы кеше биредә берәү генә, анысы да теркәү эше белән генә шөгыльләнә. Аңлашыла ки, бөтен вак, шул ук вакытта әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү кебек җаваплы эш җитәкчелек җилкәсенә төшә.

- Әллә техника ремонтлауны оештыр, әллә торак фонды белән шөгыльлән - икегә ярылырга кирәк,- дип көрсенә берләшмә управляющие М.Ю.Жемков.

## ХАТАДАН ХАЛИ ТҮГЕЛ

Газета укучы дөрес аңласын, без берләшмәне ак та пакъ итеп күрсәтергә җыенмыйбыз.

- Безнең оешмага карата канәгатьсезлек белдерүне гадәттән тыш нәрсә санамыйм, хатадан хали түгел без,- диде безгә баш инженер А.Н.Кузнецов та. «Сельхозтехника»да төзәтелгән техника гарантия срогында ук «чатакласа» һәм бу турыда берләшмәгә хәбәр ителгән очракта махсус комиссия оештырыла. Тикшерүнең нейтраль вәкил - «Гостехнадзор» белгече катнашында үткәрелүе гаепле якны гадел билгеләргә мөмкинлек бирә. Быелның 9 аенда «Сельхозтехника»да төзәтелгән техникага карата ике тапкыр рекламация бирелгән. Берсендә берләшмә үз гаебен таныган: двигательне үз хисапларына ремонтлаганнар алар. Икенчесендә двигательнең хуҗалыкта бөтенләй икенче төрле май салу сәбәпле сафтан чыкканлыгы ачыкланган.

Билгеле инде, «брак» җибәрүчеләргә карата кискен таләпләр куелгач, биредә эшләүчеләр дә үз хезмәтләренә җитдиерәк карарга тырышалар. Шулай итмәгәндә, берничә айлап хәләл хезмәт хакыңны ала алмау түгел, кесәңдә булганын да чыгарып түлисе була бит.

***

*Алда телгә алынганнардан бер нәтиҗә туа: «Сельхозтехника» әһәмиятле эш башкара. Аның белән хуҗалыклар арасындагы аңлашылмаучылыкка сәбәп бер генә - үзара түләү мөмкинлеге булмау, икенче төрле итеп әйткәндә, замана чире.*

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Мәгълүмат Мәгълүмат

# ШОФЕР, ИСЕҢДӘ ТОТ!

***Кадерле «Дуслык»! 23 августтан соң Россиядә гамәлгә кергән штрафларның яңа тарифларын хәбәр итмәссезме икән?***

| | |
|---|---|
| Документларсыз машинада йөрү | 16700 сумнан 42000 сумга кадәр |
| Дәүләт номерлары булмаган машинада йөрү | 42000 - 84000 |
| Тормозлары яки руле төзек булмаган машинада йөрү (элеккеләре белән чагыштырганда, штраф арттырылган бердәнбер пункт) | 84000 - 250000 |
| Теркәлмәгән машина өчен | 16700 - 42000 |
| Номерлары танылмый, укылмый торган машина йөрткән өчен | 16700 - 42000 |
| Шәһәрдә сигнал бирү | кисәтү |
| Махсус сигнализация кую кагыйдәләрен бозган өчен | 418000 - 585000 |
| Тизлекне 10 - 20 км/сәг. арттыру, каешсыз йөрү, машинаның юл полосасында урнашу кагыйдәләрен бозу | 16700 - 42000 |
| Юл билгеләре һәм тамга таләпләрен үтәмәү, тиешсез урында туктау һәм туктап тору | 42000гә кадәр |
| Светофорның тыючы сигналына үтеп керү, «кирпеч» астына керү, узу яки кире борылу кагыйдәләрен бозган өчен | 84000гә кадәр |
| Тамганың тоташ сызыгын кисеп үтү, тимер юл кичүләрендә кагыйдә бозулар, алдан үтү хокукы булган җәяүлеләргә һәм машиналарга юл бирмәү | 84000 - 167000 |
| Велосипедчылар һәм җәяүлеләрнең юл йөрү кагыйдәләрен бозганнары өчен | 8400 - 42000 |
| Материаль зыян китергән шул ук бозулар | 42000 - 84000 |
| Кешеләр яралануга китергән шул ук бозулар | 42000 - 87000 |
| Зур габаритлы һәм куркыныч йөкләр ташу кагыйдәләрен бозган өчен | 84000 - 250000 |
| Светофорларны, юл өслеген һәм корылмаларны вату, хәрәкәт өчен комачау тудыру | 84000 - 417000 |

## Туберкулез һөҗүм итә

Бүген Россиядә туберкулез белән 2 миллион 200 мең кеше авырый һәм авыручылар саны арта тора. ИТАР - ТАСС хәбәр итүенчә, 1996 ел башыннан туберкулез белән авыручылар үткән елның шул чоры белән чагыштырганда, 4 процентка арткан. Балалар арасында бу сан 11 процент тәшкил итә. Быел 49 мең русияле туберкулез йоктырган. Бу авыруның иң күп таралган регионнары - Дагстан, Тува, Ичкерия, Ингушетия, Осетия, Якутия һәм Алтай крае. Туберкулез аеруча төрмәләрдә киң таралган. Соңгы 6 ел эчендә бу медик - социаль авыру төрмәләрдә һәм лагерьларда 50 мәртәбә, ә үлем - җитем 18 мәртәбә арткан. Бу авыру белән көрәшү ел саен Русиягә 11 - 12 триллионга төшә.

## РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ КЕМ БУЛЫР?

**2000 елда Россия Президенты кем булыр икән?**

- Яңа йөз еллыкка керү алдыннан Россиягә 2000 елга ил президентын сайлауларда үзенең хәзергесен һәм киләчәген тагын бер кат күздән үткәрергә кирәк. Июль аенда «АиФ» атналыгы үткәргән сорашып - белешү күрсәткәнчә, анда катнашучыларның 26 проценты «үз кандидаты»ның фамилиясен күрсәткән. 32 проценты лаеклы кандидатура таба алмаган. 42 проценты җавап бирергә авырсынган. «2000 елда Россия президентлыгына кандидатлар» арасында иң зур процент җыйганы - Г.Зюганов (23,8 процент). Аннан кала Б.Немцов - 21,8, А.Лебедь - 15,8, Г.Явлинский - 10,7, Ю.Лужков - 5,2, В.Жириновский - 4,4, Б.Ельцин - 3,4, А.Чубайс - 1,6, В.Черномырдин - 1,4 процент.

«Кандидатлар» арасында Е.Гайдар, М.Горбачев, Б.Громов, А.Лукашенко, Е.Примаков, Н.Рыжков, Г.Старовойтова, И.Хакамада һ.б.да бар. Шулардан 2000 елга җиңәсе кешенең кем булуын сайлаулар гына күрсәтә ала.

## БЫЕЛ АШЛЫК УҢДЫ

**Татарстанда иген уңды быел. Әле былтыргы ашлыкның да тотылып беткәне юк бит. Кая куеп бетерерләр икән шулкадәр байлыкны?**

- Әйе, быел әйбәт уңыш үстерелде. Дөрес, зур - зур мәйданнарда орлыклар сөрлекте, ә бу урып - җыюны кыенлаштырды. Чыннан да, складларда әле 400 мең тонна былтыргы ашлык та бар. Эш шунда, Татарстанда ашлыкка сатып алу бәяләренең югары булуы сәбәпле, узган ел Россиянең башка төбәкләре белән чагыштырганда аны урнаштыру белән эш кыенрак килеп чыкты. Хәзер ашлыкны урнаштыру каналы табылды кебек. Аерым алганда, республика азык - төлек биржасы төзелә һәм ул ашлык белән сәүдә итүне тәртипкә салырга тиеш. Кыенлык белән үстерелгән уңышны черетергә юл куймас, әлбәттә.

## ПАСПОРТНЫ 14 ЯШЬТӘН

**Кайсыдыр газетадан, быелдан башлап паспорт 14 яшьтән бирелә, дип укыган идем.**

Яңа Гражданлык кодексы буенча, рәсәйлеләр хезмәт эшчәнлеген 14 яшьтән башлый алалар, ә паспорт булмагач, моны эшләп булмый, дигән аңлатма алынды Россия Федерациясе Президенты каршындагы гражданлык мәсьәләләре комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү бүлегеннән. Күптән түгел хөкүмәт кабул иткән карарда 14 яшьлекләргә паспортлар бирүнең быел 1 октябрьдән башланачагы әйтелгән иде. Ыгы - зыгы булмаячак, чөнки бу процедура 2005 елның 31 декабренә кадәр дәвам итәчәк.

**Сез үз хокукларыгызны беләсезме?**

## КИМЧЕЛЕККӘ ЮЛЫКСАГЫЗ...

1997 елның 13 маенда РФ хөкүмәте тарафыннан 575 номерлы «Товарларда җитди кимчелекләр булганда кулланучының аларны алыштыру таләбе канәгатьләндерелергә тиешле техник катлаулы товарлар исемлеген раслау турында»гы карары кабул ителде. Аның нигезендә «техник катлаулы» товарлар исемлегенә түбәндәгеләр кертелә:

1. Автотранспорт чаралары һәм аларга номер агрегатлары.
2. Мотоцикллар, мотороллерлар.
3. Снегоходлар.
4. Катерлар, яхталар, көймә моторлары.
5. Суыткычлар һәм суыту камералар.
6. Автомат кер юу машиналары.
7. Төп периферия җайланмалары булган персональ компьютерлар.
8. Авыл хуҗалыгы тракторлары, мотоблоклар, мотокультиваторлар.

Карарда шулай ук кулланучы товарда җитди кимчелеккә юлыккан очракта товарны тапшырып, аның акчасын кире кайтарып алырга хаклы дип тә әйтелә.

## Акыл гимнастикасы



ДЮКФПда берничә ел инде шахмат уйнарга өйрәнү түгәрәге эшли. Анда мәктәп яшендәге балалар шөгыльләнә. Шунысы куанычлы: балаларның шахматка мәхәббәте елдан - ел арта бара. Хәзер без балаларны бу түгәрәккә язылырга чакырабыз.

Һәр елны көз ир - атлар арасында шәһәр беренчелегенә шахмат ярышлары башлана. Группаларны комплектлау төгәлләнеп килә. 15 ноябрь көнне 14 сәг.тә ДЮКФП бинасында ярышта катнашучыларны җыярга планлаштырабыз. Биредә шахмат турнирына регламент билгеләнә, башка мәсьәләләр дә каралачак. I тур 16 ноябрьдә көндезге 10 сәг.тә башлана.

Шахмат дөньясына рәхим итегез!

**А.КОСТИН.**

## КОТЛЫЙБЫЗ

*Фома авылында яшәүче кадерле әниебез **Хәлимә Вәгыйзь кызы Мәхмүтовага** бүген 60 яшь тула. Аны олы юбилее белән тәбриклибез һәм бәхетле озын гомер, шатлык, тынычлык, күтәренке кәеф телибез.*

***Иң изге теләкләр белән балалары.***



## Белдерүләр

### САТАБЫЗ

**Шәһәр үзәгендә ике катлы йортның икенче катында ике бүлмәле фатир («Березка» ашханәсе артында) һәм кулланышта булган җиһаз.**
Адрес: Козлов ур., 7 - 6, 16 сәг.тән соң.

***

**20 метрлы койма орнаменты.**
Адрес: Советская ур., 137 - 1, 17 сәг.тән соң.

***

**Әрҗәле УАЗ - 3303.** Адрес: Спартак ур., 9.

***

**Әйбәт хәлдәге УАЗ - 469.** Тел.: 2 - 10 - 68.

***

**Сыер һәм бозау. Урта Камышлы авылында Осиповага мөрәҗәгать итәргә.** Тел.: 2 - 35 - 56.

***

**Материаллары белән 2,5 - 5 метрлы мунча бурасы.** Елаур авылында тел.: 4 - 32 - 28.

***

**Төрле размерда цинклаган тимер листлар.**
Тел.: 5 - 37 - 32.

***

**1992 елгы ВАЗ - 21043, 21000 км. юл үткән.**
Тел.: 2 - 23 - 24.

***

**1984 елгы ВАЗ - 21013, 65000 км. юл үткән, 12,5 млн. сум.** Адрес: Дружба ур., 74 - 39.

***

**Ак төстәге ВАЗ - 21099, двигатель 1500, 5ле күчерү тартмасы.** Кошки авылы, Дружба ур., 10 адресына мөрәҗәгать итәргә.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Шарапова Раилә Сәлим кызы исеменә 1 нче мәктәп тарафыннан бирелгән А -786952 номерлы аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.**

***

**1979 елда Әхмәдиев Радик Әдип улы исеменә бирелгән тракторчы - машинист таныклыгын югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.**

***

**1994 нче елның 18 нче маенда Каравыл Тавы урта мәктәбе тарафыннан Ятманов Юрий Валерьевич исеменә бирелгән 258997 номерлы аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга.**

***

**Мәдрәсә мөгаллименә гаиләсе белән яшәп тору өчен фатир яки йорт кирәк.** «Камыр Батыр» бакчасы янындагы Норлат мәдрәсәсенә мөрәҗәгать итәргә.

***

**Германиядә эшләнгән кухня гарнитурлары, Аргентинада җитештерелгән нутрия туннарына заказлар кабул итәбез.** Тел.: 5 - 17 - 79, лицензия Б - 97 № 004778.

***

**Табигый газдан файдаланучы барлык норлатлыларга алынган табигый газ өчен исәп - хисапны тикшерү һәм килешүләр төзү өчен «Норлатгаз» ЭПУсына килергә кирәк. Үзегез белән газ һәм техник хезмәт күрсәтү өчен түләү турында квитанцияләрегез булу шарт.** Безнең адрес: Гыйматдинов ур., 158.

«Норлатгаз» ЭПУсы администрациясе.

***

**Ике бүлмәле фатир ике берәр бүлмәлегә алмаштырыла.** Адрес: Московская ур., 5 - 9.

***14 нче ноябрь көнне 10 сәг.тә район мәдәният йортында Ульяновск күн комбинаты аяк киемнәре сату ярминкәсе оештырыла. Киң ассортиментта ирләр, хатын - кызлар, балалар, мәктәп аяк киемнәре, шулай ук галантерия товарлары сатылачак.***

***Идел Буе региональ наркология үзәге***

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көне 21ноябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ Сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.




БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.